КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 11 апрель г.Казань № 447

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2015 ел, 11 июнь, 427 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2015 ел, 11 июнь, 427 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 17 май, 321 нче; 2016 ел, 9 июль, 465 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 610 нчы; 2017 ел, 24 август, 598 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанс тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанс тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән субсидия бирү тәртибен расларга.»;

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм аның гамәле 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.»;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибендә:

Тәртип исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанс тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән субсидия бирү тәртибе»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрофинанс оешмасы исемен үзгәртү турында» 2016 ел, 5 май, 284 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыру максатларында эшләнде һәм «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә

булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә (алга таба – Фонд) субсидия бирү механизмын билгели.»;

2 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«социаль өлкәнең инновацияләр үзәге эшчәнлеген тәэмин итү;»;

бишенче абзацта «экспортка юнәлтелгән» сүзләрен «экспортка йөз тоткан» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен хезмәтләр күрсәтү оештырыла торган бизнес өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күп функцияле үзәкләрен төзү һәм үстерү.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кластерлы үстерү һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары кооперациясе үзәген үстерү.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Субсидия бирү Татарстан Республикасының тиешле финанс елына һәм план чорына бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән күздә тотылган бюджет йөкләмәләре чикләрендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыру өчен башкарыла.»;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Фондка бирелә торган субсидия күләме «2018 елга һәм 2019 һәм 2020 елларның план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнә.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзү планлаштырылган айның беренче көненә Фонд туры килергә тиеш булган таләпләр:

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре юк;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән, кайтару буенча түләү вакыты чыккан бурычы һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында бүтән түләү вакыты чыккан бурычы юк;

үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында түгел.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3 пункт өстәргә:

«3.3. Кайтарырга субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләре әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән максатлар нигезендә Килешүдә раслана.»;

5 пункты түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Субсидияне бирү Вәкаләтле орган һәм Фонд арасындагы субсидия бирү турында килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешү Вәкаләтле орган тарафыннан расланган форма буенча әлеге Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән документларны Вәкаләтле органга тапшырган көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә төзелә.

Килешүдә субсидиянең күләме, аның максатчан билгеләнеше, аннан файдалану турында хисапны тапшыру тәртибе һәм вакытлары, агымдагы финанс елында субсидияне алучы субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен кире кайтару тәртибе очраклары, Вәкаләтле орган, дәүләт финанс контроле органнары һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Фондның субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүгә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга Фондның ризалыгы, Фондның әлеге Тәртип шартларын үтәве турында нигезләмәләр күздә тотыла.

Субсидия бирүнең нәтиҗәлелек күрсәткечләре (максатчан күрсәткечләре) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасына кушымта нигезендә билгеләнә Килешүдә күздә тотыла.»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Субсидия (субсидиянең өлеше) Килешүдә билгеләнгән очракларда Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Фонд тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.»;

9.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.1. Әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән субсидияне (субсидиянең өлешен) кире кайтару вакытлары бозылганда Вәкаләтле орган эш көннәрендә исәпләнгән 8 көн эчендә субсидиянең кире кайтарылырга тиешле акчасын законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кайтару буенча чаралар күрә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин